ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№174 от «06» 05 2020 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2019 нчы елның
25 нче июлендә кабул ителгән
203 нче номерлы карарына үзгәрешләр
кертү турында

Мамадыш районы прокуратурасының 2020 елның 15 апрелендәге № 02-08-02-2020 номерлы протесты, Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 январендәге “Торак урынны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында” 47 нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 25 июлендәге 203 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә бинаны, торак урынны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт, торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Хезмәт алучылар: юридик һәм физик затлар - муниципаль һәм хосусый торак фондының торак урыннары милекчеләре (яллаучылар), бакча йортлары милекчеләре.

1.2. 2.5 нче пунктның 5 нче подпунктында «проект-эзләүче» сүзен «махсуслаштырылган» сүзенә алмаштырырга.

2. Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә секторына өч эш көне эчендә әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы М.Р.Хуҗаҗанов

0000010424